# КАРАР

**30 ноябрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 27 һәм 30 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Югары Чура авылынын Вахитов , Пионер урамнарына юлларга вак таш түшәү (сатып алу, күчереп йөртү, вак таш түшәү); проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары Чура авылының Вахитов урамында вак таш җәелгән юлларын ремонтлау;

-Югары Чура авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру махсус җайланмаларны сатып алу, урам яктырткычлары, яктырткычлар урнаштыру;

-Югары Чура авылынын Мәктәп урамына юл билгеләре алу

- Югары Чура авылына насослар сатып алу;

-Югары Чура авылы чишмәсен төзекләндерү; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-чишмә янындагы мәйданчыкны тигезләү;

-Югары Чура авылынында Вахитов урамына автомобиль күперен төзү; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары Чура авылында Вахитов урамындагы җәяүле күперне ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-төзекләндерү һәм буа төзү Югары Чура авылы проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-Югары Чура авылындагы юлларны кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү;

- Югары Чура авылы урамнарында корыган агачларны һәм куакларны кисү, санитар эшкәртү; махсус техника табу; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-Югары Чура авылында видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 475 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 273 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 273 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

   - Югары Чура авылынын Вахитов , Пионер урамнарына юлларга вак таш түшәү (сатып алу, күчереп йөртү, вак таш түшәү); проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

   - Югары Чура авылының Вахитов урамында вак таш җәелгән юлларын ремонтлау;

   -Югары Чура авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру махсус җайланмаларны сатып алу, урам яктырткычлары, яктырткычлар урнаштыру;

   -Югары Чура авылына юл билгеләре алу;

   - Югары Чура авылына насослар сатып алу;

   -Югары Чура авылы чишмәсен төзекләндерү; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

   -Югары Чура авылынында Вахитов урамына автомобиль күперен төзү; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары Чура авылында Вахитов урамындагы җәяүле күперне ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
-төзекләндерү һәм буа төзү Югары Чура авылы проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
-Югары Чура авылындагы юлларны кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү;
- Югары Чура авылы урамнарында корыган агачларны һәм куакларны кисү, санитар эшкәртү; махсус техника табу; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
-Югары Чура авылында видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру;
-Югары Чура авылында урамнарны асфальтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Чура авылындагы Вахитов урамына вак таш җэю (вак таш сатып алу һәм салу), "проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

«КАРШЫ»

«РИЗА»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары Чура
авыл җирлеге башлыгы

И.Н. Алексеев